**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«11» май 2022 ел № 24/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыны «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалану өчен арендага бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 30 октябрендәге 20/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Аренда шартларында муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай районы прокуратурасының 2022 елның 25 февралендәге 02-08-02 номерлы протесты нигезендә Биклән авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыны «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалану өчен арендага бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 30 октябрендәге 20/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3 пунктта «җир кишәрлегеннән файдаланган өчен» сүзләре алдыннан «күчемсез милек объекты астындагы» сүзләрен өстәргә;

1.2. 3.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Мөлкәт арендасын түләү буенча ташлама шәхси эшмәкәрләр булмаган, «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга, мөлкәт арендалаучы һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары булып торучы яки социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре, Россия Федерациясе дәүләт программаларында (ярдәмче программаларында), Татарстан Республикасы дәүләт программаларында (ярдәмче программаларында), муниципаль программаларда (ярдәмче программаларда) билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелә, Күрсәтелгән ташлама түбәндәге күләмнәрдә аренда түләвен билгеләүдән гыйбарәт:

аренданың беренче елында - сатуларлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

аренданың икенче елында - сатуларлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

аренданың өченче елында - сатуларлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 25 проценты;

аренданың дүртенче елында - сатуларлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 50 проценты;

аренданың бишенче елында - сатуларлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 75 проценты;

аренданың беренче елында - сатуларлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 100 проценты».

1.3. 3.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6 пунктта каралган шартларда төзелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен, мөлкәтне арендалау шартнамәсе буенча арендачы йөкләмәләренең үтәлмәвенә бәйле рәвештә яки әгәр арендачы әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган критерийларга туры килүдән туктаган очракта вакытыннан алда өзгәндә, дәүләт мөлкәтеннән фактта файдалануның бөтен вакыты сату нәтиҗәләре буенча мөлкәтне арендалау килешүендә билгеләнгән аренда бәясенең 100 проценты күләмендә түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының (tukay.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Бикләнавыл җирлеге Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе М.Ш.Сәхбеев